
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№6
Февраль 2020 г.

## С Днем защитника Отечества!

*Дорогие мужчины!*

С Днем защитника Отечества,
С отважным, мужественным днем!
Вы — честь и слава государства,
Храните вы наш отчий дом!

Крепки, смелы и справедливы,
Душой добры и молчаливы.
Вы — гордость наша, наша ценность,
Мужская сила, воля, смелость!

Пусть будете всегда здоровы,
Крепки, надежны, как основа.
Спасибо вам за вашу стойкость,
За мир, защиту, вашу зоркость!




*С уважением, редколлегия газеты!*

## Февраль - месяц мужества

***По традиции в феврале проходит месячник, посвященный Дню защитника Отечества. В нашей школе прошла тематическая неделя, посвященная этому празднику.***

Во всех классах прошли мероприятия, уроки Героизма, на которых воспитанники более подробно узнали о том, кто такие защитники Отечества, о профессиях, связанных, прежде всего с риском, доблестью и отвагой ради защиты своей Родины и, конечно же, всех тех, кто в настоящее время стоит на страже нашей безопасности

18 февраля прошла встреча с подполковником запаса, участником боевых действий в Афганистане Багаутдиновым Сергеем.

21 февраля в нашей школе прошёл конкурс “А ну-ка, парни” среди 9-11 классов, приуроченный празднику День Защитника Отечества.

20 февраля учащиеся нашей школы сдавали Всероссийского физкультурно-спортивного комплекса ГТО.

Команда “Юнармейцы” нашей школы участвовала в интиликтуальной игре “РосКвиз”, проведенная местным отделением партии “Единая Россия” и сотрудниками музея “Казан арты”. В ходе мероприятия обучающиеся познакомились с историей возникновения праздника, подвигами наших предков во имя независимости Родины.

Можно с уверенностью говорить о том, что этот праздник очень важен для нас. Ведь эта дата объединяет в себе историю воинских подвигов и героев российской армии.

21 февраля в рамках акции “Поздравь ветерана”, юнармейцы нашей школы присутсвовали на награждении ветерана ВОВ Галиева-Масхуда Галиевича юбилейной медалью “75 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг”.

### Интересно знать!

- Великая отечественная война длилась 1418 дней и ночей.
- Вторая мировая война была самой кровавой, масштабной и разрушительной в истории человечества.
- Количество участвовавших в войне стран — 61
- Площадь военных действий — 22 млн. кв. км.
- Число жертв около 100 млн. только убитых.
- Материальный ущерб , в том числе прямые военные расходы - 1384.

### В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең, тууына 114 ел... | 2 |
| Школа имени Марата Лотфуллина | 2 |
| Наша гордость | 3 |
| Билен кысып буган диләр... | 4 |
| Солдатта булган диләр... | 4 |
| Направления внеурочной деятельности | 5 |

## *Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең, тууына 114 ел...*



***Гомерем минем моңлы бер жыр иде,***
***Үлемем дә яңрар жыр булып.***
***Муса Җәлил***

Бу исемне телгә алуга, күз алдына ниндидер гадәттән тыш кеше килгәндәй була.

Ул – ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнең азатлыгы өчен курку белмәс көрәшче дә, үлемне ирләрчә батыр каршылаган каһарман да.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка жибәрүләрен сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә. Ләкин 1942 нче елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай аның лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый.

Соңгы сулышына кадәр Муса Җәлил туган иленә тугры кала.

Әлеге шигырь әсирлектә вакытта иҗат ителгән. Ул аны кызы Чулпан өчен язган.

**Дару**

Кыз авырды, тәне ут шикелле,
Сулыгып-сулыгып тибә йөрәге.
Гаҗиз калды доктор, авыру кызга
Бер дару да файда бирмәде.
Яткан чакта авыру түшәгендә,
Авыр төшләр белән саташып,
Ачылды да ишек, юл киеменнән
Кайтып керде кызның атасы.
Маңгаенда батыр яра эзе
Һәм билендә поход каешы.
Еллар буе кызны зарыктырды
Шул атаның йөрәк сагышы.
Таныш йөзне күреп кыз елмайды:
«Әти!» - диеп, аңа үрелде.
Шул төнне үк йөздән тире чыкты,
Кызу кайтты, тәне сүрелде.
Гаҗәпләнмә, доктор, күреп кызның
Дару эчми кинәт савыгуын.
Белмәдеңме жирдә «сөю» дигән
Иң куәтле дәва барлыгын!

1943, октябрь

# Школа имени Марата Лотфуллина

**Лотфуллин Марат Альтафович родился 21 апреля 1968 года в городе Норильске Красноярского края. Марат поступил в АСОШ №2 в третий класс.**

В музее нашей школы есть альбом классного руководителя Марата – Егоровой Татьяны Александровны, сохранившей и собравшей все фотографии класса, в котором учился Марат. После окончания 8-го класса Марат твёрдо решил учиться в своей школе и окончить десять классов. Он красиво говорил на родном языке. . Впереди были выпускные экзамены, вступительные экзамены в Казанский строительный институт на отделение ПГС. Учёба на первом курсе, сессия, призыв в ряды Советской Армии…



Служил Марат в 191-ом мотострелковом отдельном полку в танковом батальоне, в танковой роте. Полк находился в пригороде города Газни, в древней столице Афганистана.

Служил Марат в 191-ом мотострелковом отдельном полку в танковом батальоне, в танковой роте. Полк находился в пригороде города Газни, в древней столице Афганистана.

Вот что пишет старшина первой роты, где проходил службу Марат. «Наша рота была боевой. Марат был резервным водителем танка. Он очень остро переживал, что его не посылают на операции. Перед каждой операцией просил, чтобы его взяли».

С первого боя показал себя храбрым, добросовестным. В начале апреля должен был состояться выезд на операцию одного взвода. И как всегда, более половины роты пришло к командиру, капитану Глякову Владимиру Денисовичу, проситься на операцию. Среди них был и Марат. Сначала его не включили в список. Однако после неоднократных просьб он был включён. В бою Марат вёл себя достойно.

Этот день стал роковым в жизни Марата. 8 апреля 1987 года оборвалась его жизнь. Он пролил кровь, но честно выполнил присягу. 8 апреля 1989 года в фойе школы состоялся торжественный митинг, посвященный открытию мемориальной доски с именем Лотфуллина Марата, с тех пор его имя носит наша школа.

**Ислам** Габдрахманов,
**6А класс**

# Наша гордость

***Наконец, прошли все республиканские этапы олимпиад. И каждая из них помогла выявить лучших учеников в определенных предметах. Лучшими среди лучших стали... МОЛОДЦЫ!!!***

| | |
|---|---|
| Литература | Шарипов Рузаль |
| Татарский язык | Аглиева Адиля |
| | Никитина Эльзана |
| | Шарипов Рузаль |
| Английский язык | Газизов Данил |
| МХК | Газизов Данил |

## Фоторепортаж с мероприятий текущего месяца














# Билен кысып буган дилэр...

**Минем эти Марат Габдрахманов, армияда һава юллары оборонасы подразделениясендә (ПВО) хезмәт итте.**

Ул 1999 елдан 2001 елга кадәр, башта Владикавказда 6 ай, аннан соң Волгоградта хемәт бер ел да дүрт ай хезмәт итә. Шушы ике ел эчендә ул Урал машинасында йөргән. Алар айга 4 тапкыр автоматтан атарга, Астрахан өлкәсенә полигонга йөргәннәр. Әти хезмәттәшләре белән гел аралашып тора, очрашуларга да бара.

Әтинең солдат хезмәтендә булган вакытларын без аның истәлеккә алып кайткан альбомындагы фоторәсемнәрен карап, сөйләшеп утырырга яратабыз. Энем Инсаф белән икебез дә зур үскәч, эти кебек солдат булырга хыялланабыз.




Армиядән кайкач, эти МСО оешмасында эшли. Әнием Миляүшәгә өйләнгәнче, өй сатып ала. 2006 елда әнием белән гаилә корып, 2007 елда мине, 2009 елны энем Инсафны алып кайталар.

Минем этием—бик тырыш, эшчән кеше. Ул безгә дип яңа өй төзеде. Хәзер эти юллар төзү и дәрәсендә эшли, үз эшен бик ярата. Без энем белән эти яңашәсендә булырга, аңа ярдәм итәргә тырышабыз.

Мин Армиядә булган барлык этиләрне, дәү эти һәм бабайларны 23 нче февраль бәйрәме белән тәбрик итәм. Аларга сәләмәтлек, озын гомер, күңел күтәренкелеге, эшләрендә уңышлар, гаиләләрендә тынычлык булуын телим.

Туган илебез күге һәрчак аяз булсын. Сугышлар булмасын! Җир шары тыныч, дөньялар имин булсын. Әтиләребез өчен чын күңелдән горурланып яшик! **Ислам Габдрахманов**

**6А класс**

# Солдатта булган дилэр...

**Сугыш. Нинди куркыныч сүз. Гаиләләргә һәр көн, һәр минут сагыш һәм хәсрәт китереп, солдатлар коралга алына. Иң куркынычы – синең илдә, шәһәрдә, авылда, туганнарың белән булган вакытта. Һәр буынның үз сугышы: Бөек Ватан сугышы, Әфганистан, Чечня...**

Бу сугышлар безнең йөрәкләрдә авыр чагылыш таба. Бу коточкыч сүз минем гаиләне дә читләтеп үтмәде. Без ул сугыш һәм кешеләр турында нәрсә беләбез? Бернәрсәдә, диярлек, белергә тиеш, үткәнне онытырга ярамый.

Әтием, Сиражиев Инсаф Васил улы, Чечняда сугышчан хәрәкәтләрдә катнашкан.

Мин аның ничек сугышканын сорагач, ул һәрвакыт дәшми тора иде.

Ниһаять, аның турында язарга булдым. Андагы "кайнар нокталар", командировкалар, турында сөйләвен сорагач, эти бик озак каршы торды. Тырыша торгач, этине сөйләштерү бәхетенә ирештем.

Эти сәйләгәндә үзем дә хәрби бәрелеш башлану, Чечня территориясендә барган сугышлар турында кузалладым. Иң якын кешем – әтием турында күп нәрсә белдем. Хәзер аның ни өчен кайчагында нәрсә турында да булса уйлануын аңлыйм, сугыш турындагы фильмнарны башкача карый һәм тормышны ныграк бәяли. Ул хәзер бу дәһшәтле сугышта күпме үлем күргән. Ә аңа нибары унсигез яшь иде...

Әтием, Сиражиев Инсаф Васил улы, 1977 елның 17 июнендә гади авыл гаиләсендә туган. Гади авыл балалары кебек хәрәкәтчән, актив, шат күңелле малай булып үскән. Авылның теләсә кайсы эшен намус белән башкарган. Балачактан ук армиядә хезмәт итү турында хыялланган. "Бу тормыш мәктәбен үз – үзен хөрмәт иткән һәр малай үтәргә тиеш!" – этием шулай ди. Моның өчен ул яхшы укырга тырышкан һәм спорт белән шөгыльләнгән.

1995 нче елның 30 маенда этием армиягә алына. Сигез ай эчендә эти ант кабул итә һәм яшь сугышчы курсын уза. Тиздән аңа, башка солдатлар кебек үк, ирекле тәртиптән Чечняга командировка тәкъдим итәләр. Ул риза була.

Чечняга дүрт йөз кешене хәрби эшелон белән җибәрәләр.

Хабаровсктан алып Чечен Республикасына кадәр егерме биш тәүлек тукталышсыз баралар. Чечня аларны бик кырыс каршылый, тирә-юньдәге җимереклек куркыта, хезмәт итү дә җиңел булмый. Әти армиядә хезмәт итүе турында сөйләргә яратмый. "хезмәт елларын күп нәрсәгә : түземлек, хезмәт сөючәнлеккә, сер тота белергә, эшне намус белән һәм пөхтә башкарырга, тормыштагы төрле хәлләргә әзер булырга өйрәттеләр , - ди этием. Ә менә хезмәттәшләре, дуслары турында сөйләргә ярата. "Дуслык, ярдәмчеллек, - безгә сугышта патроннардан да ким кирәкми иде" – ди ул.

Мин этидән сугыштан соң аның тормышка мөнәсәбәт үзгәргәнме икәнен сорагач: " Безгә, егетләргә, ул вакытта унсигез яшь иде, билгеле, тормыш башкача иде, - дип җавап бирде. Әти хикәятен тәмамлады һәм, ниһаять, ниндидер авыр йөкне күңелдән төшергәндәй елмаеп куйды. Ә минем йөрәгем этигә карата мәхәббәт һәм аның чын герой булуы белән горурлану хисләре белән тулды.

**Аделя** Шарбатова,
**8Б класс**

# Направления внеурочной деятельности

*Лучший способ сделать ребенка хорошим – это сделать его счастливым*

***Оскар Уайльд***

1.«Ансамбль барабанщиц «Ритм»»
Руководитель Мухаметгалиева А.Ф.



2. Объединения «Волейбол», «Баскетбол», «Легкая атлетика» Руководитель Шакиров Б.Ф.

3. «Реальная математика» . Ру-



ководитель Мухаметзянова Г.Я.

4. «Мир рукоделия» Руководи-



тель Хайрутдинова Э.Р.



“Яшь журналист” түгәрәге житәкчесе Ибраева Р.Х.

Фикерле белгәннәр генә дөрес сорау куя белә.
Элисо Кинг.

Мәктәптә эшләп килүче “Яшь журналист” түгәрәге бала шәхесен, аның танып-белү, коммуникатив, иҗади сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән.

Алга куелган төп максат һәм бурычлар: аралашучанлык, иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

Бу максатлар дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек вакытында тормышка ашырыла. Без, түгәрәктәге 15 укучы белән бергәләп газетага язу серләренә, тема табу, фактлар туплау; материалны кәгазгә төшерү, редакцияләү осталыгына төшенергә тырышабыз. Киләчәктә һәр укучының үз фикерен әйтергә хокукы булуын күрү сәләте һөнәр сайлауга да бер этәргеч буласына ышанабыз. Журналист булмасалар да, тормышларында ярдәм итми калмас дигән ышаныч белән эшлибез.

Эшне системалы алып барганда, төрле текст редакторы, график редактор белән, цифрлы техника белән эш йөртә белгән, күптөрле яңа программаларны үзләштергән, мәгълүмат белән эшли белүче, газетага мәкалә, репортаж, интервью язу мөмкинлекләренә ия булган актив, сәләтле укучылардан команда туплана.

Без “Мәктәп пульсы” газетасын чыгарганда Microsoft Publisher программасын бик яратып кулланабыз. Һәрбер укучының үз вазифасы бар. Алар арасында: мөхәррир, дизайнер–бизәүче, корреспондентлар, фотохәбәрче, корректорлар, версткага салучылар, газетага язмаларын даими биреп баручы хәбәрчеләребез бар.

Версткага салучылар PageMaker, Adobe Photoshop, Microsoft Office Word, Microsoft Office Publisher программаларында эшли белүче Информацион һәм коммуникатив технологияләрне яхшы үзләштергән егетләр. Рус теле һәм әдәбияты укытучылары белән тыгыз элемтәдә торабыз. Аларның биргән киңәшләрен истә тотып эшләргә тырышыбыз, чөнки газета ике телдә чыгарыла. Шулай бергә нәтиҗәле эшлибез. Планнар корып, тагын да файдалырак итәргә омтылабыз.

“Мәктәп пульсы” газетасы 1917 елдан бирле яңа форматта ай саен чыгып килә.

**Азат** Исмәгыйлев**,**
8Б класс



# Ана теле бер булыр

***...Офыктагы маяк булып алга чакыр***
***Татар теле, Тукай теле,Туган телем!..***
*Акъегет*

Көндәлек тормышта без еш кына үзебез сөйләшә торган телне яки телләрне табигый бер нәрсә итеп кабул итәбез. Гаять зур әһәмияткә ия телебез тормыш-көнкүрешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Фикерләү, тәртип һәм үзебезнең тормышыбызның рәвешенә, ысулына әйләнә. Шуңа күрә дә без аның төп функциясен - нәкъ менә аралашу һәм аңлашу функциясен онытып җибәрәбез. Бу тел - сабыйлык, изге гаилә тәҗрибәсе, башлангыч социаль мөнәсәбәтләр теле.







21 февраль—Халыкара туган тел көне уңаеннан районда һәм мәктәптә күптөрле чаралар үткәрелде.

Укучылар бу көнне барлык сыйныфларда милли рухта күңел күтәренкелегендә төрле кызыклы уеннар уйнадылар.

Район күләмендә үткәрелгән “Мин яратам сине, Татарстан” шигырь конкурсында уңышлы чыгыш ясап, Хәйретдинова Эльвина-1, Мөхәммәтгалиева Ралина, Гарипова Зөһрә 3 урынга лаек булдылар.

**Камил** Гарифуллин,
6 А сыйныфы.

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Азат Исмагилов
***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов
***Корректор*** Ислам Габдрахманов
***Редколлегия*** Камиль Гарифуллин
Раниль Заляев

***Адрес:*** ул. Мост овая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2